КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 22 март г.Казань № 161

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 317 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 317 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 29 декабрь, 660 нчы; 2006 ел, 19 июнь, 312 нче; 2010 ел, 31 май, 419 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 26 октябрь, 890 нчы; 2011 ел, 23 декабрь, 1060 нчы; 2012 ел, 2 июнь, 466 нчы; 2012 ел, 10 октябрь, 846 нчы; 2013 ел, 19 март, 185 нче; 2013 ел, 4 декабрь, 955 нче; 2013 ел, 11 декабрь, 974 нче; 2014 ел, 4 июнь, 376 нчы; 2016 ел, 19 март, 150 нче; 2016 ел, 29 октябрь, 796 нчы; 2017 ел, 3 февраль, 58 нче; 2017 ел, 20 апрель, 232 нче; 2017 ел, 18 декабрь, 1008 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктның икенче абзацында «430,928» саннарын «452,146» саннарына алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы турындагы нигезләмәдә:

3.3 нче пунктта:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министрлык эшчәнлеге өлкәсендә дәүләт программаларының дәүләт заказчысы функцияләрен үти;»

егерме бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләр советы һәм Татарстан

Республикасының муниципаль районнары (шәһәр округлары) арасында транспорт һәм юл хуҗалыгы өлкәсендәге килешүләр кысаларында Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген мониторинглауны һәм аның индикаторларын анализлауны гамәлгә ашыра;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасының дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар сатып алу, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә Министрлык ведомствосы буйсынуындагы учреждениеләргә карата дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар сатып алу, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә контракт системасы турындагы законнар һәм башка норматив хокук актлары үтәлешен ведомство тикшерүендә тотуны законнар белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыра.»;

4.1 нче пункттагы дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт программаларын тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелгән акчаны бүләргә һәм аны сарыф итүне тикшерүдә тотуны гамәлгә ашырырга;»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы структурасында «тармак аудиты һәм тариф сәясәте бүлеге» дигән сүзләрне «тармак аудиты һәм предприятиеләр эшчәнлеген анализлау бүлеге» дигән сүзләргә алыштырырга.

2. Бу карарның 1 нче пунктындагы икенче абзацның гамәле 2017 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин